**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

02.12.2024 | № 1458

2025 елга Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы гамәлдәге норматив хокукый актларга экспертиза уздыру планын раслау турында

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 31.05.2018 №385 карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе нигезендә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы гамәлдәге норматив хокукый актларга экспертиза уздыру планын 1нче кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/ .
3. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны икътисад бүлегенә йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Г.Гыйниятуллин

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 02 декабрендәге 1458 номерлы карарына кушымта

2025 елга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының гамәлдәге норматив хокукый актларына экспертиза уздыру планы

| № т/с | Экспертиза ясалырга тиешле гамәлдәге норматив хокукый акт исеме | Хокукый актны эшләүне гамәлгә ашыручы җайга салучы орган, бүлекчә исеме | Норматив хокукый актка экспертиза уздыру срогы | Норматив хокукый актка экспертиза турында бәяләмә проектын тапшыру срогы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының инвестиция климатын яхшырту буенча Иҗтимагый советы турында" Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башлыгының 2023 елның 17 октябрендәге 99 номерлы карары | ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге | Апрель | Май |
| 2 | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләр чикләрен билгеләү Кагыйдәләрен раслау турында»2013 елның 28 маендагы 247 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында" 23.04.2024 ел, № 227 карары | ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге | Август | Сентябрь |